Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел №109

Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2018 елның “28” августындагы 70 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2018 елның «28» августындагы 70 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2018 елның «5» декабрендәге 78 номерлы, 2020 елның «11» декабрендәге 11 номерлы, 2022 елның «27» октябрендәге 56 номерлы, 2022 елның «14» декабрендәге 61 номерлы, 2024 елның «26» июнендәге 101 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Аппак
авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 167 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 18 607» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 19 173 |
| Башлык урынбасары | 13 991» |

2. Әлеге карарны Аппак авылы, Тынычлык урамы, 71 нче йорт; Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Аппак авыл
җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова